**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 4 март № 133

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составын раслау турында» 2005 ел, 6 сентябрь, 438 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составын раслау турында» 2005 ел, 6 сентябрь, 438 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 гыйнвар, 21 нче; 2007 ел, 20 август, 399 нчы; 2007 ел, 6 декабрь, 690 нчы; 2009 ел, 25 май, 335 нче; 2009 ел, 24 декабрь, 871 нче; 2010 ел, 31 август, 688 нче; 2012 ел, 19 июнь, 523 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 19 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Р.Т.Борһановны, И.Җ.Миңнәхмәтовны, В.Г.Шәйхразиевны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айрат Ринат улы Зариповны;

Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Александрович Леоновны;

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе Наил Гамбәр улы Мәһдиевне (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\133.doc